ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
30.12.2019

КАРАР
ПР-332

Актаныш муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитеты баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

Актаныш муниципаль районы "Үзәкләштерелгән бухгалтериясе" муниципаль бюджет учреждениесе, "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе" муниципаль бюджет учреждениесе, "Актаныш муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе" муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм аны оештыру турында нигезләмә.

Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларыннан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмә.

2. Әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификация эшләрен башкарганда, 2019 елның 31 мартына хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге ПР-90 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре һәм белгечләре, баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары һәм аны оештыру турында»гы карарнв үз көчен югалткан дип таныр

"Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" Актаныш муниципаль районы муниципаль бюджет учреждениеләре җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары баш хисапчылары һәм хисапчылары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларыннан тыш) вазыйфаларын әлеге карар белән тәңгәл китерүне тәэмин итәргә;

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе И. И. Габдулхаев

Расланган
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән
30.12. 2019 ел № ПР-332

**Актаныш муниципаль районы**
**"Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында"**
**Нигезләмә**

1. "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтериясе" МБУ җитәкчеләре һәм белгечләре өчен хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында - Нигезләмә, "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" Актаныш муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладыннан, тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт окладына ай саен өстәмә, эш интенсивлыгы, акчалата бүләк, матди ярдәм, ел саен түләүле отпуск, эш нәтиҗәләре буенча бер тапкыр түләнә торган түләүләр, хезмәт хакына ай саен өстәмә түләүләрдән тора.

3. "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (башка җирле үзидарә органы) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 23 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 21 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш хисапчы) | | 21 500 |
| Бүлек башлыгы | 17 700 | 17 700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 15 300 | 15 300 |

| | | |
|---|---|---|
| Эш башкаручы | 14 000 | 14 000 |

МБУ "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" нең 1 категорияле белгече вазыйфасы хисапчы вазыйфасына үзгәртелә.

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерияне штат расписаниесенә кертү шарты булып, җитәкче урынбасарының вазыйфасы структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штат саны булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләре штатта 5 берәмлектән дә ким булмаган санда булырга тиеш.

4. Актаныш муниципаль районы "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Мәдәният учреждениеләре үзәкләштерелгән бухгалтериясе", "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" муниципаль бюджет учреждениеләре, Актаныш муниципаль районы "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ җитәкчеләре һәм белгечләре белән берлектә:

1) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә түләү:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 процент күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләү.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән булса, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм түләнә, эштән азат ителгән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча.

Еллык түләүле отпуск биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр түләнә торган түләү беренче эш елында календарь елда башкарылган чорга пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә кадәр эшкә керү белән исәпләнә.

4) муниципаль учреждение җитәкчесенә ай саен вазыйфаи окладның 10 процент күләмдә акчалата бүләкләү;

җитәкче урынбасарына, муниципаль учреждение бүлекләре башлыкларына хезмәт окладының 5 процентына кадәр айлык акчалата бүләкләү;

Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесенә ай саен вазыйфаи окладның 20 процент акчалата бүләкләү;

5) матди ярдәм билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә;

*6)* эш нәтиҗәләре буенча премия (премия түләүнең шартлары, чиратлылыгы, күләмнәре хезмәт өчен түләүнең гамәлдәге шартларыннан чыгып билгеләнә);

7) "Актаныш муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе" МБУ дә программист вазыйфасын премияләүнең гамәлдәге шарты саклана.

5. Актаныш муниципаль районы "Актаныш муниципаль районы

бухгалтерия" МБУ җитәкчеләре һәм белгечләренең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ - җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - җитәкчегә һәм белгечкә вазыйфаи окладларны түләүгә акчалар суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү суммасы;

*P* - җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык премия фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);

$n$ -җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ - хезмәткә түләү буенча түләүләр.

Расланган
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән
30.12. 2019 ел № ПР-332

**Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары баш хисапчыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаларына кертелгән вазыйфаларыннан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында**
**Нигезләмә**

1. Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакы турында әлеге нигезләмә (алга таба - хисапчылар) хисапчылар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Хисапчыларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм ел саен түләүле отпуск, эш нәтиҗәләре буенча премияләр бирелгәндә бер тапкыр түләнә торган хезмәт хакыннан тора.

3. Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 15 700 сум | 17 000 сум |
| Хисапчы | - | 14 500 сум |

Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының штат расписаниесенә хисапчы вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлек халкының саны 3,5 меңнән артык кеше тора.

**Авыл җирлекләре башкарма комитетларында баш белгеч вазыйфасы 14 000 сум оклад белән хисапчы вазыйфасына үзгәртелә.**

4. Хисапчыларга билгеләнә:

1) тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә түләү:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү;

күрсәтелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнә, эштән азат ителгән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Ел саен түләүле отпуск бирелгәндә, хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган түләү эшнең беренче елында календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә кадәр эшкә керү белән исәпләнә.

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

*5)* эш нәтиҗәләре буенча премия (шартлар, чиратлылыгы, премия түләү күләмнәре хезмәт өчен түләүнең гамәлдәге шартларыннан чыгып билгеләнә).

5. Хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \text{P} * (1 + t);$$

биредә:

$FOT$ - хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - хисапчыга вазыйфаи окладлар түләүгә бер айга акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү суммасы;

*P* - хисапчыларның еллык премия фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);

$n$ - хисапчыларның штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ - хезмәткә түләү буенча түләүләр.